| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от 09 марта 2016 г. г. Казань № 50

Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының 2015 елның 5 февралендәге 29 санлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының дәүләти җайга салынучы товарларга (хезмәт күрсәтүләргә, эш башкаруларга) бәяләр (тарифлар, өстәлмәләр, өстәмә хаклар) күләмен куллануның дөреслеген һәм нигезлелеген региональ дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тотуны тормышка ашыру дәүләт функцияләрен үтәү буенча Административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе законнарына тәңгәлләштерү максатыннан

б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының 2015 елның 5 февралендәге 29 санлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының дәүләти җайга салынучы товарларга (хезмәт күрсәтүләргә, эш башкаруларга) бәяләр (тарифлар, өстәлмәләр, өстәмә хаклар) күләмен куллануның дөреслеген һәм нигезлелеген региональ дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тотуны тормышка ашыру дәүләт функцияләрен үтәү буенча Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дәүләт комитеты тарафыннан Дәүләт функциясен үтәү түбәндәгеләргә нигезләнеп башкарыла:

Россия Федерациясе Гражданнар кодексына («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 05.12.1994, №32, 3301ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексына (алга таба – РФ КоАП) («Россия Федерациясе законнары җыентыгы», 07.01.2002,

№1 (1бүлек), 1 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Су кодексына («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 05.06.2006, № 23, 2381 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Урман кодексына («Россия Федерациясе законнар җыентыгы»,11.12.2006, №50, 5278 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Табигый монополияләр турында» 1995 елның 17 августындагы 147- ФЗ санлы Федераль законга («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 21.08.1995, №34, 3426 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендагы 89-ФЗ санлы Федераль законга («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 29.06.1998, №26, 3009 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ санлы Федераль законга («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 05.04.1999, №14, 1667 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35- ФЗ санлы Федераль законга («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 31.03.2003, №13, 1177 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Коммуналь комплекс оешмаларының тарифларын җайга салу нигезләре турында» 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ санлы Федераль законга («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 03.01.2005, №1 (1 бүлек), 36 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт күзәтчелеген (контрольне) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ санлы Федераль законга (алга таба - 294-ФЗ санлы Федераль закон («Россия Федерациясе законнар җыентыгы» 29.12.2008, №52 (1 бүлек), 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дару чаралары әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ- санлы Федераль законга («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 19.04.2010, №16, 1815 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190 - ФЗ санлы Федераль законга («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 02.08.2010, №31, 4159 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Транспорт чараларын техник карау турында һәм Россия Федерациясенең аерым законнарына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 1 июлендәге 170-ФЗ санлы Федераль законга («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 04.07.2011, №27, 3881 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Аерым төр юридик затлар тарафыннан товарлар, эш, хезмәт күрсәтүне сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ санлы Федераль законга («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 25.07.2011, №30 (1 бүлек), 4571 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы Федераль законга («Россия Федерациясе законнар җыентыгы» 12.12.2011, №50, 7358 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ санлы Федераль законга («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 30.12.2013, №52 (I бүлек), 7007 ст. , кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 28 февралендәге №221 санлы Россия Федерациясе Президенты Указына(«Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 06.03.1995, №10, 859 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә үзйөрешле машиналарның һәм техниканың башка төрләренең техник торышына дәүләт күзәтчелеге турында»1993 елның 13 декабрендәге 1291 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына(«Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 20.12.1993, №51, 4943 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы №239 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 13.03.1995, №11, 997 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Газга һәм аны җитештерү өчен чимал чыгаруга бәяләрне дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 15 апрелендәге №332 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 24.04.1995, №17, ст.1539 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә торак фондын дәүләт исәбенә алу турында» 1997 елның 13 октябрендәге №1301 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», №42, 20.10.1997, 4787 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясе территориясендә газга бәяләрне, аны транспортировкалау буенча хезмәт күрсәтүләргә тарифларны һәм газ белән тәэмин итү җайланмаларын газ тарату челтәрләренә тоташтыру өчен түләүләрне дәүләти җайга салу турында» 2000 елның 29 декабрендәге. №1021 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 08.01.2001, №2, 175 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Электр энергиясен тапшыру буенча дискриминация кулланмыйча хезмәт күрсәтү мөмкинлеген бирү һәм әлеге хезмәтләрне күрсәтү Кагыйдәләрен, электр энергетикасында оператив-диспетчерлык идарәсе буенча дискриминация кулланмыйча хезмәт күрсәтү мөмкинлеген бирү һәм әлеге хезмәтләрне күрсәтү Кагыйдәләрен, күпләп сату базарының сәүдә системасы администраторына дискриминация кулланмыйча хезмәт күрсәтү мөмкинлеген бирү һәм әлеге хезмәтләрне күрсәтү Кагыйдәләрен, электр энергиясен кулланучыларның, электр энергиясен җитештерүче объектларның, шулай ук челтәр оешмаларына һәм башка

затларга, шулай ук электр челтәрләренә караган электр челтәрләре объектларының энергия кабул итеп алучы җайланмаларын технологик яктан тоташтыру Кагыйдәләрен раслау турында» 2004 елның 27 декабрендәге №861 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 27.12.2004, №52 ( 2 бүлек), 5525 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Транспорт терминалларында, портларда, аэропортларда табигый монополияләр субъектлары хезмәт күрсәтүләренә һәм эчке су юлларының инфраструктурасыннан файдалану буенча хезмәт күрсәтүләргә бәяләрне (тарифларны, җыемнарны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү турында» 2008 елның 23 апрелендәге 293 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 28.04.2008, №17, 1887 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә бәя билгеләү нигезләре һәм тарифларны, өстәлмәләрне һәм чик индексларны җайга салу тәртибе турында» 2008 елның 14 июлендәге 520 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына(«Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 21.07.2008, №29 (2 бүлек), 3518 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнарының тарифларны дәүләти җайга салу өлкәсендә табигый монополия субъектларының эшчәнлеген дәүләти җайга салуда һәм контрольдә тотуда катнашуы турында» 2008 елның 10 декабрендәге 950 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына («Россия Федерациясе законнар җыентыгы»,15.12.2008, №50, 5971 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Тормыш өчен кирәкле һәм мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларына бәяләрне дәүләти җайга салу турында» 2010 елның 29 октябрендәге 865 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына («Россия Федерациясе законнар җыентыгы»,08.11.2010, №45, 5851 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Транспорт чараларына техник карау үткәрү турында» 2011 елның 5 декабрендәге 1008 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 12.12.2011, №50, 7397 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр(тарифлар) өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 23.01.2012, №4, 504 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Электр энергиясен ваклап сату базарларының функцияләве, электр энергиясен куллану режимын тулысы белән һәм (яисә) өлешчә чикләү турында» 2012 елның 4 маендагы 442 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 04.06.2012, №23, 3008 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләр хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 29.10.2012, №44, 6022 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406-ФЗ санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 20.05.2013, №20, 500 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт тарафыннан җайга салынган бәяләр(тарифлар) өлкәсендә дәүләт контроле(күзәтчелеге), шулай ук Россия Федерациясенең кайсыбер актларын үзгәртү һәм үз көчен югалткан дип тану турында» 2013 елның 27 июнендәге 543 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына («Россия Федерация законнар җыентыгы», 08.07.2013, №27, 3602 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы Законына («Республика Татарстан», №110, 30.05.2008);

«Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерү, аларны саклау, кире кайтару, күчергән һәм саклаган өчен чыгымнарны түләү тәртибе турында» 2012 елның 17 маендагы 24-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы Законына («Республика Татарстан»«, № 100, 26.05.2012);

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне тәртипкә салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126- ЗРТ санлы Татарстан Республикасы Законына («Республика Татарстан», N 186, 20.12.2014);

«Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты мәсь-әләләре» 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» 04.08.2010, №29, 1195 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында транспорт чараларына техник карау үткәрү өчен түләүнең иң чик күләмен һәм техник карау талоны дубликатын рәсмиләштергән өчен чыгымнарның иң чик күләмен билгеләү турында» 2011 елның 27 декабрендәге 1079 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» 31.01.2012, №8, 0296 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү поставщиклары тарафыннан өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәт күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 елның 29 декабрендәге 1053 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең

республика органнары норматив актлары җыентыгы», 30.01.2015, N 7-8, 0201 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

1.7 пунктының 1.7.2 пунктчасын түбәндәге реакцияда бәян итәргә:

«1.7.2. Тикшерү үткәрергә вәкаләтле булган вазифаи затлар түбәндәгеләрне үтәргә бурычлы:

- Россия Федерациясе законнары нигезендә үзләренә тапшырылган мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү, ачыклау һәм юкка чыгару вәкаләтләрен вакытында һәм тулы күләмендә үтәү;

- Россия Федерациясе законын, үзләренә карата тикшерү үткәрелә торган юридик затның, хосусый эшмәкәрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү;

- тикшерүне Дәүләт комитеты рәисенең (рәис урынбасарының) тикшерү үткәрү турындагы боерыгы нигезендә, тикшерү билгеләнешенә таянып, үткәрү;

- тикшерүне фәкать хезмәт бурычларын үтәгән вакытта гына үткәрү, күчмә тикшерүне фәкать хезмәт таныклыкларын, Дәүләт комитеты рәисенең (рәис урынбасарының) тикшерү үткәрү турындагы боерыгы күчермәсен күрсәтеп үткәрү;

- тикшерү үткәргәндә җитәкчегә, башка вазифаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, хосусый эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү үткәрүне карап торуга комачауламау һәм тикшерү предметына керүче мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирү;

- тикшерү үткәрүдә катнашкан җитәкчегә, башка вазифаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, хосусый эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына караган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру;

- җитәкчене, башка вазифаи затны яки юридик затның вәкаләтле вәкилен, хосусый эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыру;

- җитәкчене, башка вазифаи затны яки юридик затның вәкаләтле вәкилен, хосусый эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән таныштыру (әлеге абзацының таләбе 2016 елның 1 июленнән гамәлгә керә);

- ачыкланган бозу фактлары буенча чаралар күрү барышында бу чараларның тиешле хокук бозуларга туры килүен исәпкә алу, шулай ук гражданнарның, шул исәптән хосусый эшмәкәрләрнең, юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен нигезсез чикләүгә юл куймау;

- үз гамәлләре буенча Россия Федерациясе законында билгеләнгән тәртиптә юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр тарафыннан шикаять белдерелгәндә, гамәлләрнең нигезлеген раслау;

- 294-ФЗ санлы Федераль законда билгеләнгән тикшерү үткәрү срокларын үтәү;

- юридик заттан, хосусый эшмәкәрдән Россия Федерациясе законы нигезендә тапшыру күздә тотылмаган документлар һәм башка мәгълүматларны таләп итмәү;

- күчмә тикшерү үткәрер алдыннан җитәкче, башка вазифаи зат яки юридик затның вәкаләтле вәкиле, хосусый эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле үтенече белән

тикшерү үткәрүгә нигез итеп алынган бу Регламент нигезләмәләре белән таныштыру;

- тикшерүләрнең исәпкә алу кенәгәсенә үткәрелгән күчмә тикшерү турында язып кую (әлеге абзацның таләбе 2016 елның 30 июненә кадәр гамәлдә була);

- юридик зат, хосусый эшмәкәрдә булагн очракта тикшерүләрнең исәпкә алу кенәгәсенә үткәрелгән күчмә тикшерү турында язып кую (әлеге абзацының таләбе 2016 елның 1 июленнән гамәлгә керә)».

1.7 пунктының 1.7.3 пунктчасында:

дүртенче абзацтагы «(әлеге пункт таләбе 2015 елның 1 июленнән гамәлдә була)» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацтагы «(әлеге пункт таләбе 2015 елның 1 июленнән гамәлдә була)» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абазацлар белән тулыландырырга:

«- юридик заттан, хосусый эшмәкәрдән документлар һәм башка мәгълүматлар, шул исәптән башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертерлгән дәүләт ораганнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар кармагында булган рөхсәт документларын тапшыруны таләп итү (әлеге таләб 2017 елның 1 январеннан гамәлгә керә);

- юридик заттан, хосусый эшмәкәрдән элегрәк Россия Федерациясе закон таләпләре нигезендә тапшырылган һәм (яки) дәүләт яки муниципаль информацион системаларында, реестрларында һәм регистрларында булган информацияне тапшыруны таләп итергә (әлеге таләб 2017 елның 1 январеннан гамәлгә керә).»;

1.8. пунктының 1.8.1 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле абазацлар белән тулыландырырга:

«- башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки дәүләт ораганнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар тарафыннан аларның кармагында булган Дәүләт комитеты ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларныда алган документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән танышу (әлеге абзац таләбе 2016 елның 1 июленнән гамәлгә керә);

- ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларныда соралган документлар һәм (яки) мәгълүматларны Дәүләт комитетына үз инициативасы буенча тапшырырга (әлеге абзац таләбе 2016 елның 1 июленнән гамәлгә керә);

- әгәр тикшерү № 294-ФЗ Федераль законының 26.1 статьясы нигезләмәләрен бозып еллык планлы тикшерүләр уздыру планына кертелгән диеп саналса, аңа карата тикшерүләрне еллык планлы тикшерүләр уздыру планынынннан төшереп калдыру турында гаризаны Дәүләт комитетына тапшырырга»;

2.1.5 пунктчаның дүртенче абзацындагы «2.1.3» саннарын «2.1.2» саннарын алыштырырга;

2.3.1 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«кече эшмәкәрлек субъектына карата тикшерү үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүмат алу кирәк булган очракта тикшерү үткәрү Дәүләт комитеты рәисе (рәис урынбасары)

тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру өчен кирәк булган һәм ун көннән дә артык булмаган срокка туктатылырга мөмкин. Тикшерү уздыруының кабат туктатылуы рөхсәт ителми.

тикшерү уздыруының туктатып тору срогы гамәлдә булган чорда күрсәтелгән тикшерү белән бәйле булган дәүләт Комитеты вазифаи затларының гамәлләре кече эшмәкәрлек территорияләрендә, биналарында, төзелмәләрендә, корылмаларында, башка объектларында туктатыла (әлеге абзац таләпләре 2016 елның 1 июленә кадәр гамәлдә була)»;

2.3.2 пунктчасының икенче абзацында «һәм җылылык белән, су белән белән тәэмин итү, су чыгару, каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү өлкәсендә» сүзләрен «, җылылык белән, су белән белән тәэмин итү, су чыгару һәм каты көнкүреш калдыклары белән эш итү өлкәсендә» сүзләренә үзгәртергә;

2.4.2 пунктчасының бишенче абзацында «һәм җылылык белән, су белән белән тәэмин итү, су чыгару, каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү өлкәсендә» сүзләрен «, җылылык белән, су белән белән тәэмин итү, су чыгару һәм каты көнкүреш калдыклары белән эш итү өлкәсендә» сүзләренә үзгәртергә;

түбәндәге эчтәлекле яна 2.4.2[1] пунктчасы белән тулыландырырга:

2.4.2[1]. «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ санлы Федераль законының 4 статьясы нигезләмәсе нигезендә кече эшмәкәрлек субъектларына чутланган юридик затларга, хосусый эшмәкәрләргә карата план буенча үткәрелүче тикшерүләр 2018 елның 31 декабренә кадәр үткәрелми. Әлеге абзацта күрсәтелгән затларга карата элегрәк закон көченә кергән Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар Кодексы нигезендә билгеләнгән тупас бозу кылган өчен административ җәза яки дисквалификацияләү рәвешендәге административ җәза билгеләү турында карар кабул ителеп тикшерү үткәрү тәмамлануы датасыннан алып тикшерүенең нәтиҗәләре буенча карар кабул ителгәннән соң өч елдан кимрәк вакыт үткән булу турында мәгълүмат булган очракта Дәүләт комитеты ел саен үткәрелә торган планлы тикшерүләр уздыру планын төзегендә әлеге Регламентның 2.4.2 пункты нигезендә мондый затларга карата ел саен үткәрелә торган планлы тикшерүләр планына тикшерүне кертү турында карар кабул итергә хокуклы.»;

2.4.4 пунктчасының беренче абзацында «һәм җылылык белән, су белән белән тәэмин итү, су чыгару, каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү өлкәсендә» сүзләрен «, җылылык белән, су белән белән тәэмин итү, су чыгару һәм каты көнкүреш калдыклары белән эш итү өлкәсендә» сүзләренә үзгәртергә;

3 бүлекнең 1 таблицасын яңа редакциядә бәян итергә:

| №№ п/п | Мәҗбүри таләпләр куелган эшчәнлек төрләре | Мәҗбүри таләпләр тәгъбирләнеше | Мәҗбүри таләпне билгеләүче норматив -хокукый акт |
|---|---|---|---|

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 1. | Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләре (тарифлары) ТР башкарма хакимияте тарафыннан билгеләнгән товарлар сату, хезмәт күрсәтү | җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге | «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190 - ФЗ санлы Федераль законның 5,7 статьялары;<br>«Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләр хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары |
| 2. | Электр энергетикасы өлкәсендә бәяләре (тарифлары) законда билгеләнгән тәртиптә билгеләп куелган товарлар сату, хезмәт күрсәтү | җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге | «Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35- ФЗ санлы Федераль законның 21 статьясы 4 бүлеге ;<br>«Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары |
| 3. | Халыкка, шулай ук торак-эксплуатация оешмаларына, күпфатирлы йортлар белән идарә итүче оешмаларга, торак-төзелеш кооперативларына һәм торак милекчеләре ширкәтләренә халыкның көнкүреш ихтыяҗлары өчен (торак пунктларда торак булмаган биналарны арендалау-чылар өчен һәм автотранспорт чараларына салу өчен газдан башка) сатыла торган газ сату | җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге | «Газга һәм аны җитештерү өчен чимал чыгаруга бәяләрне дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 15 апрелендәге №332 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарының 2 пункты |
| 4. | Гражданнарга, идарә итүче оешмаларга, торак,торак-төзелеш кооперативларына һәм торак милекчеләре ширкәтләренә торак өлкәсендә халыкның көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен оештырылган башка махсус кулланучылар кооперативларына каты ягулык, көнкүрештәге мичләр өчен ягулык һәм керосин сату | җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге | «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы №239 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5. | Шәһәр җәмәгать транспортының бөтен төрләрендә, метрополитен-ны да кертеп, һәм шәһәр яны транспортында (тимер юл транспортыннан кала) пассажир-лар йөртү һәм багаж ташу | җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге | «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы №239 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары; |
| 6. | шәһәр яны тимер юл транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу | җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге | «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы №239 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары; |
| 7. | Республикаара (Россия Федера-циясе чикләрендә өлкәара) һәм республика эчендәге маршрутлар буенча автомобиль транс-портында, таксины да кертеп, пассажирлар йөртү һәм багаж ташу | җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге | «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы №239 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары; |
| 8. | Җирле авиалинияләрдә, җирле суларда һәм кичүләрдә елга транспорты белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу | җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге | «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы №239 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары; |
| 9. | Оешу-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә сәнәгагый тимер юл транспорты оешмалары, федераль тимер юл транспорт оешмала-рыннан гайре, һәм башка хуҗалык оешмалары тарафыннан керә торган тимер юлларда күрсәтелүче транспорт хезмәтләре | җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге | «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы №239 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары; |
| 10. | Фармацевтика эшчәнлеген алып баруга лицензиясе булган күпләп сату оешмалары, даруханә оешмалары, хосусый эшмәкәрләр тарафыннан тормыш өчен кирәкле һәм мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратлар сату | җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге | «Дару чаралары әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ- санлы Федераль законның 6 статья-сы; «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы №239 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 11. | Бәяләре (тарифлары) ТР башкарма хакимияте органнары тарафыннан билгеләнгән су белән тәэмин итү, су бүлү өлкәсендә товарлар сату һәм хезмәт күрсәтү | җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге | «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы Федераль законның 35 статьясы;<br>«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406-ФЗ санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары |
| 12. | Бәяләре (тарифлары) ТР башкарма хакимияте органнары тарафыннан билгеләнгән каты көнкүреш калдыклары белән эш итү өлкәсендә хезмәт күрсәтү | Җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге. Региональ операторлар, каты көнкүреш калдыклары белән эш итүче региональ операторларының мәгълүмат ачу стандартларының таләпләрен үтәүю. | «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ санлы Федерального законы 24.12 статьясының 5 өлеше; 24.9 статьясының 9 өлеше<br>«Коммуналь комплекс оешмалары-ның тарифларын җайга салу нигезләре турында» 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон;<br>«Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә бәя билгеләү нигезләре һәм тарифларны, өстәлмәләрне һәм чик индексларны җайга салу тәртибе турында» 2008 елның 14 июлендәге 520 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары |
| 13. | Дәүләт һәм муниципаль социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре тарафыннан халыкка социаль хезмәт күрсәтү | җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге | «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы №239 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары; |
| 14. | Гомуми белем бирү мәктәпләрендәге, профтехучилещелардагы, урта махсус һәм югары уку йортларындагы җәмәгать туклануы предприятиеләрендә продукция (товарлар) сату | җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге | «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы №239 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары; |
| 15. | Балалар азыгы продуктлары (азык концентратларын да кертеп) сату | җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге | «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы №239 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 16. | Татарстан Республикасы территорясендә урнашкан челтәрле оешмаларның электр челтәрләренә технологик тоташтыру буенча хезмәт күрсәтү | бәяләр һәм (яисә) әлеге түләүнең күләмен билгеләүче стандартлаштырылган тариф ставкаларын куллануның дөреслеге | «Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35- ФЗ санлы Федераль законның 24 статьясы 3 бүлеге |
| 17. | Татарстан Республикасы территориясендә торак фондына техник инвентаризация уздыру | җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге | 1997 елның 13 октябрендәге №1301 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган торак фондын дәүләт исәбенә алу турындагы Нигезләмәнең 8 пункты |
| 18. | Орлык җитештерү өлкәсендә түләүле хезмәт күрсәтүләр | җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге | 1998 елның 15 октябрендәге №1200 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Россия Федерациясендә авыл хуҗалыгы үсемлекләренең сортларын һәм орлыкларын контрольгә алу турындагы Нигезләмәнең 8 пункты |
| 19. | Тоткарланган транспорт чарасын саклау | җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге | «Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерү, аларны саклау, кире кайтару, күчергән һәм саклаган өчен чыгымнарны түләү тәртибе турында» 2012 елның 17 маендагы 24- ЗРТ санлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы |
| 20. | Тракторларның, үзйөрешле юл төзү транспортының һәм башка төр машиналар һәм аларга тагылмаларның техник торышына дәүләт тикшерүе уздыру барышында хезмәт күрсәтүләр | җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге | 1993 елның 13 декабрендәге 1291 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Россия Федерациясендә үзйөрешле машиналарның һәм техниканың башка төрләренең техник торышына дәүләт күзәтчелеге турындагы Нигезләмәнең 6 пункты |
| 21. | Транспорт чараларына дәүләт техник тикшерүен уздыру, шул исәптән техник диагностика ясау чараларыннан да файдаланып | җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге | «Транспорт чараларын техник карау турында һәм Россия Федерация-сенең аерым законнарына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 1 июлендәге 170-ФЗ санлы Федераль законның 16 статьясы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 22. | Татарстан Республикасы милкендәге су объектларын файдалануга тапшыру | җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге | 2006 елның 3 июнендәге 74-ФЗ санлы Россия Федерациясе Су кодексының 25 статьясы |
| 23. | Татарстан Республикасы милкен-дәге урман ресурсларын яисә урман кишәрлеген арендага бирү максатыннан тәкъдим итү | җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге | 2006 елның 4 декабрендәге 200- ФЗ санлы Россия Федерациясе Урман кодексының 82 статьясы |
| 24. | Татарстан Республикасы милкен-дәге җирләрдә әзерләнүче агач берәмлеген тәкъдим итү | җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге | 2006 елның 4 декабрендәге 200- ФЗ санлы Россия Федерациясе Урман кодексының 82 статьясы |
| 25. | Гражданнарга үз ихтыяҗлары өчен урман үсентеләре сату | җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге | 2006 елның 4 декабрендәге 200-ФЗ санлы Россия Федерациясе Урман кодексының 82 статьясы |
| 26. | Кадастр эшләре уздыру | җайга салынучы бәяләр күләмен куллануның дөреслеге һәм нигезлелеге | «Күчемсез мөлкәт дәүләт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ санлы Федераль законның 47 статьясы |

4 бүлекнең 2 таблицасын түбәндәге редакцияда бәян итергә:

| №№ п/п | Тикшерү үткәрү өчен тәкъдим ителгән документ | Документ формасын билгеләүче норматив-хокукый акт |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Барлык юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр тарафыннан тикшерү үткәрү барышында тәкъдим ителгән документлар исемлеге | |
| 1.1 | Гражданинның, хосусый эшмәкәрнең юридик зат законлы вәкиленең, аларның вәкаләтле вәкилләренең шәхесләрен таныклаучы документлар | |
| 1.2 | Гражданин, хосусый эшмәкәр, юридик зат мәнфәгатьләрен яклаучы затның вәкаләтләрен раслаучы документлар | |
| 1.3 | Структура подразделениеләре турындагы Нигезләмә | |
| 1.4 | Предприятиенең хисап сәясәте турындагы Нигезләмә | |
| 1.5 | Коммуналь инфраструктура (аренда, субаренда килешүләре, төп чараларны кабул итү- тапшыру актлары һ.б) системасын эксплуатацияләү хокукын раслаучы документлар | РФ статистика буенча Дәүләт комитеты Карары 21.01.2003 №7 |

| | | |
|---|---|---|
| 1.6 | Төп чараларны эксплуатацияләүгә тапшыру һәм чыгару турында, аларның баланс бәяләре һәм файдалы куллануның билгеләнгән сроклары күрсәтелгән мәгълүмат кертелгән төп чаралар исемлеге. Төп чараларны яңача бәяләүне үткәрү турында Боерык. Төп чаралар объектларын (ОС-6, ОС-6а, ОС-6б) (шул исәптән арендага алынганнары да), исәпкә алу инвентар кенәгәләре яисә беренчел исәпкә алу кенәгәләре | РФ статистика буенча Дәүләт комитеты Карары 21.01.2003 №7; Росстатның № 563 24.11.2015 елгы боерыгы РФ финанслар министрлыгы Боерыгы 13.10.2003 №91-н |
| 1.7 | Төп кенәгә (тикшерү үткәргән затларны теләге буенча, өлешчә) | РФ финанслар министрлыгы Боерыгы 30.03.2015 № 52н |
| 1.8 | Бухгалтерлык хисаплары (соңгы ике ел өчен һәм соңгы хисап бирү көненә):<br>- бухгалтерлык балансы (форма №1) тикшерү чорына РФ федераль салым инспекциясе билгесе белән<br>- табыш һәм югатулар турында хисап, хезмәт күрсәтүләр төрләренә расшифровка ясап( финанс нәтиҗәләре турында хисап) (форма №2);<br>- капитал үзгәрешләре турында хисап (форма №3 - еллык);<br>- акча средстволарының хәрәкәте турындагы хисап (форма №4- еллык);<br>- бухгалтер балансына кушымта (форма №5-еллык);<br>- еллык балански аңлатма язуы;<br>- әйләнеш-сальдо мәгълүмати исемлеге (ведомостьлары), счетларның анализлары (таләп буенча). | РФ финанслар министрлыгы Боерыгы 06.07.1999 № 43н;<br>РФ финанслар министрлыгы Боерыгы 02.07.2010 № 66н;<br>РФ финанслар министрлыгы Боерыгы 06.10.2008 № 106н |
| 1.9 | Тармак гамәли күрсәтмәләр (электр һәм җылылык энергиясен, җибәрелгән су - 6-в; ташландык суларны агызу -6-к; кайнар су белән тәэмин итү буенча хезмәт күрсәтүләр- 6-ГВС; каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү - 6-гомуми h.б.) нигезендә үзкыйммәткә хисап калькуляцияләре | РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы карары 23.02.1999 № 9 |
| 1.10 | Оешманың билгеләнгән тәртиптә танықланган исәпкә алу боерыгы күчермәсе | |
| 1.11 | Килешүләр:<br>- товарлар китергән, (хезмәт күрсәткән, эш башкарган) поставщиклар белән, шул исәптән, бәяләре җайга салынучы товарлар китергән поставщиклар белән төзелгән килешүләр;<br>- юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр, контрагентлар (абонентлар, субабонентлар) тарафыннан бәяләре законда билгеләнгән тәртиптә товарлар китерүгә, хезмәт күрсәтү-ләргә, эш башкаруга ( шул исәптән дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен) төзелгән килешүләр | |
| 1.12 | Коммуналь ресурс белән тәэмин итү чыганагы кысаларында эшчәнлекнең җайга салынган һәр төре буенча абонентлар исемлеге (һәр абонент буенча килешүдә билгеләнгән ресурс күләмен күрсәтеп) | |

| | | |
|---|---|---|
| 1.13 | Җайга салыну каралган бәяләр белән товар китергән, хезмәт күрсәткән, эш башкарган өчен исәп-хисап ясалуны раслаучы түләү документлары (счет-фактуралар, йөкнамәләр (накладнойлар), башкарылган эш актлары, бәяләрне килештерү беркетмәләре) | РФ статистика буенча Дәүләт комитеты Карары 25.12.1998 № 132;<br>РФ статистика буенча Дәүләт комитеты Карары 18.08.1998 № 88;<br>РФ Хөкүмәте карары 26.12.2011 № 1137;<br>РФ Хөкүмәте карары 08.08.2009 № 654; |
| 1.14 | Сатып алулар турында Нигезләмә. Законда билгеләнгән тәртиптә товарларны (эшне, хезмәт күрсәтүләрне) сатып алуны раслаган документлар (Россия Федерациясе законында каралган очракта). | |
| 2. | Тарифлар исәпләп чыгару барышында кабул ителгән чыгымнарның аерым статьялары буенча чыгымнарны нигезләү өчен өстәмә документлар: | |
| 2.1 | Үз ихтыяҗларына тотылган коммуналь ресурслар һәм челтәрдәге югалтулар чыгымнарын нигезләп , гамәлдәге тарифлар чорында оешманың товарларны сату һәм хезмәт күрсәтү күләмен раслаучы документлар | РФ статистика буенча Дәүләт комитеты Карары 25.12.1998 № 132;<br>РФ Хөкүмәте карары 26.12.2011 № 1137; |
| 2.2 | Гамәлдәге тарифлар чорына, төп чараларны ремонтлауга чыгымнар бүлеп биреп, чималга, төп һәм ярдәмче материалларга (шул исәптән ягулыкка һәм ягулык-май материалларына) тотылган чыгымнарны раслаучы документлар. Моңа түбәндәгеләр керә:<br>- соңгы өч елда төп һәм ярдәмче материаллардан файдалануның еллык күләмнәре динамикасы;<br>- материаллар кайтартуга килешүләр реестры;<br>- гамәлдәге тарифлар чорына агымдагы бәяләр белән счет-фактуралар;<br>-регламентлаган документларны күрсәтеп, материалларның чыгымнар нормалары һәм нормативлары. | РФ статистика буенча Дәүләт комитеты Карары 25.12.1998 № 132;<br>РФ Хөкүмәте карары 26.12.2011 № 1137; |
| 2.3 | Гамәлдәге тарифларның исәп-хисап ясау чорына хезмәткә түләү фонды күләмен раслаучы документлар:<br>-оешма хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча дәрәҗәне (разрядны) күрсәтеп, штат расписаниесе;<br>- коллектив килешү (хезмәткәрләрне һәм җитәкчеләрне акчалата бүләкләү турындагы нигезләмәләр белән);<br>- федераль, региональ яисә территориаль тармак тариф килешүе;<br>-хезмәткәрләрнең норматив санын исәпләп чыгару. | РФ статистика буенча Дәүләт комитеты Карары 05.01.2004 № 1; |

| | | |
|---|---|---|
| 2.4 | Дәүләт статистика буенча Федераль хезмәте тарафыннан расланган дәүләти статистика буенча хисапнамә формасы (соңгы ике ел өчен һәм соңгы хисап бирү көненә):<br>- халык саны, хезмәт хакы һәм хезмәткәрләр хәрәкәте турында мәгълүмат;<br>- эшчәнлек төрләре буенча халык саны һәм хезмәт хакы турныда мәгълүмат;<br>- инвестиция эшчәнлеге турында мәгълүмат;<br>- төп фондалрның һәм башка финанс булмаган активларның барлыгы һәм хәрәкәте турында мәгълүмат | Росстатның № 580 24.09.2014 елгы боерыгы<br>Росстатның №548 04.09.2014 елгы боерыгы;<br>Росстатның №296 03.07.2015 елгы боерыгы |
| 2.5 | Бердәм социаль салым буенча регрессив шкаланы исәпкә алып, тарифлар гамәлдә булган хисап периодына социаль ихтыяҗларга бүлеп алып калынган сумма исәп-хисабы. Травматизм өчен иминият взнослары күләме турында белдерү («социаль ихтыяҗларга түләүләр» маддәсе буеҥча фикер каршылыгы туса). | РФ Финанс министрлыгының 64н санлы 21.12.1998 елгы боерыгы |
| 2.6 | Тарифлар гамәлдә булган хисап периодына төп фондлар амортизациясен хисаплау, шул исәптән:<br>- төп чаралар исемлеге<br>- соңгы ике елда амортизациягә бүлеп алып калынган сумманы файдалану турында хисап;<br>- тарифлар гамәлдә булган периодка кулланылышка кертелгән объектлар буеҥча амортизация исәп-хисабы;<br>- төп чараларны яңадан бәяләү турында боерыклар;<br>- милекнеӊ базар бәясен бәяләү турында нәтиҗә;<br>- көйләнә торган периодка кадәрге чорда амортизациягә өстәп түләү туктатылган һәм тарифлар гамәлдә булган хисап периодына объектлар исемлеге һәм аларның бәясе;<br>- анализланган периодка кулланылыштан чыгарылуы планлаштырылган объектлар исемлеге һәм аларның бәясе. | РФ Финанс министрлыгының 64н санлы 21.12.1998 елгы боерыгы |
| 2.7 | Сатып алынган коммуналь ресурсларга чыгымнарны раслый торган документлар:<br>- соңгы 3 ел өчен еллык күләмнәр турындагы мәгълүмат;<br>- сатып алу килешүләре реестры;<br>- түләүне раслаучы түләү турындагы документлар. | РФ статистика буенча Дәүләт комитеты Карары 25.12.1998 № 132;<br>РФ Хөкүмәте карары 26.12.2011 № 1137; |
| 2.8 | Тарифлар гамәлдә булган хисап периодына, төп чараларны ремонтлауга бүлеп бирелгән чыгымнарны күрсәтеп, җитештерү характерындагы эшләргә һәм хезмәтләргә чыгымнар исәп-хисабы , шул исәптән:<br>- әлеге чыгымнар расшифровкасы;<br>- соңгы өчелда фактик чыгымнар турында хисап; эш башкаруга килешүләр. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.9 | Тарифлар гамәлдә булуның исәп-хисап чорындагы ремонт чыгымнарын раслаучы документлар, шул исәптән:<br>- төп җитештерү фондларына ремонт ясау чыгымнары нормативларына нигезләнеп, ремонт эшләренең хакын исәп-хисап кылу;<br>- җитештерү җиһазларының техник торышы буенча экспертиза нәтиҗәләре, техник күзәтү органнарының боерыклары, үткәрелә торган ремонт эшләренә дефектларисемлегe;<br>- подряд оешмалар белән килешүләр;<br>- башкарылган ремонт эшләренең актлары;<br>- түләүне раслаучы түләү турындагы документлар;<br>- соңгы 3 елда фактик башкарылган ремонтлар, эшнең күләмен һәм хакын күрсәтеп, тарифтаәлеге максатларга каралган финанс чаралары турында хисап. | РФ статистика буенча Дәүләт комитеты Карары 25.12.1998 № 132;<br>РФ Хөкүмәте карары 26.12.2011 № 1137; |
| 2.10 | Тарифлар гамәлдә булу чорында иминиятләштерүгә чыгымнарны раслаган документлар, шул исәптән:<br>- иминиятләштерү килешүләре;<br>- иминиятләштерелгән мөлкәт исемлеге;<br>- иминият полислары;<br>- иминият саклау программасы;<br>- соңгы өч елдагы иминият түләүләре һәм алынган финанс чараларыннан файдаланутурында хисап. | РФ Хөкхмәте карары 3.11.2011 № 916;<br>РФ Хезмәт министрлыгы карары 18.07.2001 № 56 |
| 2.11 | Мөлкәт, җиһаз, җир кишәрлекләре арендасына чыгымнарны раслаучы документлар:<br>- хосусый милек ияләре (арендага бирүчеләр) белән килешүләр,<br>- тарифлар гамәлдә булуның исәп-хисап чорындагы аренда түләүләренә исәп-хисап,<br>- түләүне раслаучы түләү турындагы документлар. | РФ статистика буенча Дәүләт комитеты Карары 25.12.1998 № 132;<br>РФ Хөкүмәте карары 26.12.2011 № 1137; |

| | | |
|---|---|---|
| 2.12 | Салымның күләмен таныклый торган документлар (салым базасы һәм салым ставкаларын нигезләүне кертеп).<br>Россия Федерациясе финанс Министрлыгы тарафыннан расланган формалар буенча хисаплар (соңгы ике ел һәм соңгы отчет датасы өчен):<br>- оешма милкенә салым декларациясе;<br>- иминият кертемнәре буенча салым декларациясе;<br>- керем салымыдекларациясе;<br>- су салымыдекларациясе;<br>- транспорт салымы декларациясе;<br>- җир салымы буенчадекларация;<br>- башка налоглар, кертемнәр, җыюлар салымыдекларацияләре һәм исәп-хисап. | РФ Федераль салым хезмәтенең №ММВ-7-11-895 24.11.2011 нче елгы боерыгы<br>РФ Финанс министрлыгының №163н 29.12.2007нче елгы боерыгы<br>РФ Федераль салым хезмәтенең №ММВ-7-3/600@ 26.11.2014нче елгы боерыгы;<br>РФ Федераль салым хезмәтенең №ММВ-7-3/497@ 09.11.2015 нче елгы боерыгы;<br>РФ Федераль салым хезмәтенең №ММВ-7-11/99@ 20.02.2012нче елгы боерыгы<br>РФ Федераль салым хезмәтенең №ММВ-7-11/696@ 28.10.2011нче елгы боерыгы<br>РФ Федераль салым хезмәтенең №ММВ-7-3/353@ 04.07.2014нче елгы боерыгы |
| 2.13 | Тарифлар гамәлдә булуның исәп-хисап чорында әйләнә-тирә мохитне пычрату өчен түләүне исәп-хисаплауны, чыгарып ташлауларның (урнаштыруларның) фактик күләмен һәм гамәлдәге ставкаларны күрсәтеп, раслаучы документлар. | Ростехнадзорның № 204 05.04.2007 елгы боерыгы;<br>РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы карары 23.02.1999 № 9<br>РФ статистика буенча Дәүләт комитеты Карары 25.12.1998 № 132;<br>РФ Хөкүмәте карары 26.12.2011 № 1137; |

| | | |
|---|---|---|
| 2.14 | Цех, гомум җитештерү, гомум хуҗалык чыгымнарын раслаучы документлар (чыгым элементлары шифрларын чишү һәм хезмәт күрсәтү төрләре буенча бүленеш (предприятиенең исәпкә алу сәясәтенә нигезләнеп), шулай ук аларның икътисадый нигезләрен, шул исәптән, килешүләр исемлеге һәм тарифлар гамәлдә булуның исәп-хисап чорындагы аерым элементлар буенча чыгымнарның исәп-хисабынкушып бирү белән):<br>- элемтә чыгымнары;<br>- объектларны саклауга чыгымнар;<br>- янгыннан саклануны тотугачыгымнар;<br>- кадрларны әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификацияләрен күтәрүгә чыгымнар;<br>- командировкаларга чыгымнар;<br>- вәкиллек чыгымнары;<br>- нормаль хезмәт шартларыһәм куркынычсызлык техникасын тәэмин итүгә чыгымнар;<br>- идарәче компанияне тотуга чыгымнар;<br>- юридик, консультация, мәгълүмати, аудиторлык хезмәтләргә чыгымнар;<br>- башка чыгымнар (шифрларны чишеп). | |
| 2.15 | Икътисади нигезләнгән, тарифларны (өстәлмәләрне) билгеләгәндә исәпкә алынмаган чыгымнарның, шул исәптән, җайга салуның исәп-хисап чорында продукциягә объектив һәм планнан тыш рәвештә бәяләр арту белән бәйле чыгымнарның күләмен раслаучы документлар, фактик тотылган чыгымнарның икътисади нигезләнгән булуын нигезләү белән, түбәндәгеләрне кертеп:<br>- кулланыла торган продуктларның (хезмәтләрнең) фактик күләменең планлы күләмнән артуы сәбәпләре;<br>- кулланыла торган продуктларга (хезмәтләргә) пландагыга карата бәяләр (тарифлар) артуны раслау;<br>- план буенча каралган чыгымнардан артып киткән фактик чыгымнарны финанслауның чыганаклары;<br>- әлеге заем чараларынахезмәт күрсәтү белән бәйле өстәмә чыгымнарның исәп-хисабы. | |
| 2.16 | Алынган керемнең җайга салынуның үзеннән алдагы чорында исәпкә алынган фактик кулланылышы турында хисап. | РФ Финанс министрлыгының 66н санлы 02.07.2010 елгы боерыгы |

| | | |
|---|---|---|
| 2.17 | Тарифлар гамәлдә булуның исәп-хисап чорындатүбәндәгеләргә юнәлтелгән керем күләмен раслаучы документлар:<br>- җитештерү (социаль) үсешенең программасын, шулай ук җитештерү (социаль) үсешенә чыгымнарның чишелгән шифрларын һәм хисабын кушып биреп җитештерү (социаль) үсеше.<br>- бүләкләү, шул исәптән, коллектив килешү һәм тармак тарифлары килешүләре положениеләренә сылтама биреп, факт буенча түләүләр алган эшчеләр санын күрсәтеп, социаль характердагы түләүләрнең исәп-хисабы.<br>- соңгы 3 ел өчен фактик түләнгән дивидендларны да кертеп дивидендлар түләү һәм предприятиенең дивиденд сәясәте (булган очракта).<br>- «башка максатлар» (тарифлар гамәлдә булуның исәп-хисап чорына караган килешүләр исемлеген дә кертеп, чыгымнарның чишелгән шифрлары белән)<br>Тарифлар гамәлдә булуның исәп-хисап чорында керем хисабына ясалган салымнарның исәп-хисабы, шул исәптән, бухгалтер һәм салым исәп-хисабы максатларында исәпкә алына торган керем салымының, амортизация суммаларын күрсәтеп исәп-хисабы | |
| 2.18 | Тарифлар гамәлдә булуның исәп-хисап чорына, шулай ук аннан алдагы өч чорга караган җитештерү программалары.<br>Җитештерү программаларының үтәлүе мониторингы күрсәткечләре һәм индикаторлары<br>Тарифлар гамәлдә булуның исәп-хисап чорына, шулай ук аннан алдагы өч чорга караган җитештерү программаларын тормышка ашыру өчен финанс ихтыяҗлары | |
| 2.19 | Оешманың җитештерү программасына кертелә торган инвестиция ресурсларыннан файдалану турында хисап. | |
| 3. | Җылылык тәэмин итү һәм җылылык энергиясен тапшыру сферасында эшчәнлек алып баручы оешмалар өчен өстәмә рәвештә: | |
| 3.1 | Җылылык яки электр энергиясе балансы | |
| 3.2 | Җылылык энергиясен (җылылыкны йөртүчене) тапшыру вакытындагы технологик югалтуларның Россия Энергетика министрлыгы тарафыннан расланган нормативы | |
| 3.3 | Ягулык чыгымнарының исәп-хисабыбуенча мәгълүмат:<br>- ягулык белән тәэмин итү килешүләре;<br>- ягулыкның чагыштырмачыгымнарының Россия Энергетика министрлыгында расланган нормативлары;<br>-ягулык запасларын булдыруның Россия Энергетика министрлыгында расланган нормативлары;<br>- түләүне раслаучы счет-фактуралар | РФ статистика буенча Дәүләт комитеты Карары 25.12.1998 № 132;<br>РФ Хөкүмәте карары 26.12.2011 № 1137; |
| 3.4 | гариза бирүче технологик тоташтыруга түләгәндә челтәрле оешманың керми калган керемнәрен раслаучы документлар | |
| 3.5 | Файдалы җылылык энергиясенең җибәрү структурасы | |

| | | |
|---|---|---|
| 3.6 | Җылылык энергиясенең килешенгән күләмен (Гкал) исәп-хисабы, җылылык челтәрләренең баланс иясен чикләү актлары, якларныңэксплуатацияләү җаваплылыгын чикләү актлары. | |
| 3.7 | Һәрбер җылылык энергиясе чыганагыннан (котельныйдан) кулланучыга кадәр (Җитештерү программасында күрсәтелгән абонентлар исемлегенә нигезләнеп) челтәрләрнең һәр өлешенең диаметрын һәм озынлыгын күрсәтеп, җылылык челтәрләре схемасы | |
| 3.8 | Казаннарны эксплуатацияләү буенча режим карталары. Суны казангача эшкәртү җайланмаларын эксплуатацияләү буенча һәм пар һәм су җылыту казаннарының су-химия режимын алып баруинструкцияләре һәм режим карталары | |
| 4. | Су белән тәэмин итү һәм су аеру өлкәсендә коммуналь комплекс оешмалары өчен өстәмә рәвештә | |
| 4.1 | Су үткәргеч (аерым су үткәрүчелтәре), канализация (аерым канализация челтәре) эше турында Федераль дәүләт статистикасы хезмәте раслаган формалар буенча (соңгы өч елда) мәгълүмат; | Росстатның 327 санлы 17.07.2015 елгы боерыгы |
| 5. | Электр тарату челтәрләренә технологик тоташтыруны башкара торган челтәр оешмалары өчен өстәмә рәвештә | |
| 5.1 | Энергия кабул итүче җайланмаларны челтәр оешмасының электр тарату челтәрләренә технологик тоташтыруга челтәр оешмасына бирелгән бөтен гаризалар. | |
| 5.2 | Энергия кабул итүче җайланмаларны челтәр оешмасының электр тарату челтәрләренә технологик тоташтыруга техник шартларны үтәү турында акт. | |
| 5.3 | Электр челтәрләренә баланста кем хуҗа булуы буенча чикләр үткәрү акты. | |
| 5.4 | Энергия кабул итүче җайланмаларны челтәр оешмасының электр тарату челтәрләренә технологик тоташтыруны башкару турында акт. Кулланучыларның энергия кабул итүче җайланмаларын челтәр оешмасының электр тарату челтәрләренә технологик тоташтыру чараларын үтәү буенча хезмәт күрсәтү акты. | |
| 5.5 | Энергия җайланмаларын файдалануга тапшыру акты (күрсәтелгән куәт 100 кВттан арткан очракта). | Ростехнадзорның № 212 07.04.2008 елгы боерыгы |
| 6. | Транспорт йөртү сферасында эшчәнлек алып баручы оешмалар өчен өстәмә рәвештә: | |

| | | |
|---|---|---|
| 6.1 | Билет-учет битләре. | Автобус, автомобиль-таксиларда йөрү өчен билетларның барлык төрләрен алу, саклау, бирү һәм исәп-хисапта тотуның тәртибе, пассажир һәм багажларны йөртүдән килгән керемне контрольдә һәм исәп-хисапта тоту турында инструкция (12.07.1978, РСФСР Минавтотранс тарафыннан расланган) |
| 6.2 | Пассажирларны йөртүгә билгеләнгән тәртиптә расланган муниципаль заказ. | |
| 7. | Транспорт чараларына техник күзәтү үткәрү һәм техник күзәтү талонының дубликатын бирүне гамәлгә ашыручы оешмалар өчен өстәмә рәвештә: | |
| 7.1 | Техник күзәтү үткәрү турындагы килешү. | Россия Икътисадый үсеш министрлыгының №573 14.10.2011нче елгы боерыгы |
| 7.2 | Диагностик карта, талон. | РФ Хөкүмәтенең №1008 05.12.2011нче елгы карары |
| 8. | Халыкка социальхезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашыручы оешмалар өчен өстәмә рәвештә: | |
| 8.1 | Хезмәт күрсәтүләр исемлеге | |
| 8.2 | Түләүчеләр кисемендә хезмәт күрсәтүләрне регистрацияләү журналы | |
| 8.3 | Хезмәт күрсәтүләрне сатулар китабы | |
| 9. | Гомумбелем бирүче мәктәпләр, башлангыч, урта һәм югары һөнәри белем бирү учреждениеләрендә җәмәгать туклануын тәэмин итүче предприятиеләр өчен өстәмә рәвештә | |
| 9.1 | Тикшерелә торган чор эчендә реализацияләнгән (күрсәтелгән) продукция (хезмәтләр) ассортименты | |
| 9.2 | Продуктлар, чимал белән тәэмин итүчеләр исемлеге | |
| 9.3 | Тикшерелә торган чор эчендә оешма тарафыннан җитештерелгән туклану продукциясенең калькуляцияләре, технологик карталары. | Росстандартның № 195-ст 27.06.2013 елгы боерыгы |

| | | |
|---|---|---|
| 9.4 | Приходные документы (счета-фактуры, накладные) на пищевое сырье, использованное для изготовления продукции собственного производства в проверяемый период | РФ статистика буенча Дәүләт комитеты Карары 25.12.1998 № 132;<br>РФ Хөкүмәте карары 26.12.2011 № 1137; |
| 9.5 | Технологик эшкәртүсез реализацияләнә торган сатып алына торган тауарларга керем һәм чыгым документлары | |
| 10. | Балалар өчен азык-төлек продуктларын (азык концентрантларын да кертеп) һәм тормыш өчен кирәк булган һәм иң мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларын реализацияли торган оешмалар өчен өстәмә рәвештә: | |
| 10.1 | Тикшерелә торган чор эчендә реализацияләнгән (күрсәтелгән) продукция (хезмәтләр) ассортименты. | |
| 10.2 | Продуктлар (дару препаратлары) белән тәэмин итүчеләр исемлеге | |
| 10.3 | Товарларны сатып алу килешүләре төзелгәнданәләп (күмәртәләп) сату оешмалары исемлеге (күмәртәләп сату оешмалары һәм җитештерүчеләр өчен) | |
| 10.4 | Алу бәяләре, сату бәяләре, тауарның хәрәкәте турындагы мәгълүматныүз эченә алган керем һәм чыгым документлары (счет-фактуралар, накладнойлар, бәя формалаштыру реестрлары, балалар азык-төлеге өчен склад учеты карточкалары), | РФ статистика буенча Дәүләт комитеты Карары 25.12.1998 № 132;<br>РФ Хөкүмәте карары 26.12.2011 № 1137; |
| 10.5 | Үз эченә җитештерүдәналу бәясе турындагы мәгълүматны алган документлар (балалар өчен азык-төлекне реализацияләүче данәләп сату оешмаларыннан кала) | |
| 11. | Оешманың тарифлар һәм өстәмәләр исәп-хисабы вакытында кабул ителгән чыгымнарны нигезләүче документларында аңлашылмаучанлык тудырган мәсьәләләрнеа чыклап бетерү өчен тикшерүче орган кирәк дип тапкан башка документлар. | |

5.2 пунктында:

5.2.4 пунктчаны түбәндәге редакцияда бәян итергә:

«5.2.4. Җаваплы башкаручы почта аша тапшырылуы раслана торган заказлы хат яки тапшырылуы раслана торган башка юл белән (факсимиль элемтә, алу турында билге куелган электрон почта) юридик затка, шәхси эшмәкәргә тикшерү турында боерык күчермәсен һәм тикшерү барышында күрсәтелергә тиешле документлар исемлеген җибәреп, аның тикшереләчәге турында хәбәр сала.

Дәүләт комитетының вазифаи затлары планлы докумнетар тикшерү үткәрү алдыннын җитәкчегә, башка вазифаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәһси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиленә 294-ФЗ санлы Федераль законның 26.1 статьясы нигезләмәләренең эчтәлеген аңлатып бирәләр. Планлы документар тикшерү үткәргәндә Дәүләт комитетының вазифаи заты тарафыннан юридик зат, шәхси эшмәкәрнең элеге Регламентның 2.4.2[1] пунктының 1 абзацында билгеләнгән

затларга каравы турында документлар тапшырган очракта һәм элеге Регламентның 2.4.2[1] пунктының 2 абзацында каралган нигезләр булмаган очракта планлы документар тикшерү үткәрелүе туктатыла, шул турыда Дәүләт комитеты тиешле боерык нәшер итә.

Юридик затны, шәхси эшмәкәрне – үзеннән-үзе көйләнгән оешма әгъзасын тикшергән очракта, җаваплы башкаручы планлы документар тикшерүдә катнашсын өчен үзеннән-үзе көйләнгән оешмага да хәбәр җибәрә.

Башкару вакыты: тикшерү башлануга өч эш көне кала.

Эш нәтиҗәсе: юридик затның, шәхси эшмәкәрнең документларын планлы тикшерү турында Дәүләт комитеты рәисе (рәис урынбасары) кул куйган боерык күчермәсе һәм үзкөйләнүле оешмага (үзкөйләнүле оешма әгъзасын тикшерү үткәргән очракта) җибәрелгән уведомление»;

5.2.5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«5.2.5. Юридик зат, шәхси эшмәкәр боерык күчермәсена алган вакыттан ун эш көне эчендә Дәүләт комитетына документларны планлы тикшерү боерыгында соралган документларны җибәрергә тиеш.

Әлеге документлар мөһере куелган (әгәр дә булса) һәм шәхси эшмәкәрнең вәкаләтле вәкиленең имзасы төшерелгән, юридик затның җитәкчесе, башка вазифаи заты кул куйган күчермәләр рәвешендә җибәрелә.

Юридик зат, шәһси эшмәкәр әлеге запроста күрсәтелгән документларны электрон формада, ныгытылган квалификацияле электрон имза куелып, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән рәвештә тапшырырга хокуклы.

Россия Федерациясе законнарында күрсәтелгән очраклардан кала, Дәүләт комитетына җибәрелгән документлар күчермәләренең нотариуста раслануын таләп итү тиешле түгел.

Дәүләт комитеты башка дәүләт контроль (күзәтчелеге) органнарыннан, муниципаль контроль органнарыннан ала алган мәгълүмат һәм документларны юридик заттан, шәһси эшмәкәрдән таләп итергә хокуклы түгел.

Дәүләт комитеты тикшерүләрне оештырганда һәм үткәргәндә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яки) мәгълүмәтларны түләүсез нигездә, шулай ул электрон формада, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки дәүләт ораганнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары кармагында булган элеге документлар һәм (яки) мәгълүмәтларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларнында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән срокларда һәм тәртиптә соратып ала һәм кабул итә (әлеге абзац таләбе 2016 елның 1 июленнән гамәлгә керә)»;

5.2.7 пунктчасында:

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«Юридик затның җитәкчесе, башка вазифаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле урында булмаган очракта, шулай ук тикшерелгән зат тикшерү акты белән танышуы яки танышудан баш тартуы турында расписка бирергә баш тарткан очракта, акт почта аша тапшырылуы расланган заказ хаты

итеп җибәрелә, ул исә Дәүләт комитетын эшендә сакланган тикшерү акты нөсхәсенә кушыла. Тикшерелгән затның хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашыру ризалыгы булганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тикшерү акты электрон документы формасында, шушы актны төзүче затның ныгытылган квалификацияле электрон имзасы куелып, җитәкчегә, башка вазифаи зат яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиленә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта электрон формада җибәрелгән, аны төзүче затның ныгытылган квалификацияле электрон имзасы куелган акт тикшерүче затка күрсәтелгән документның барып җитүен раслаучы рәвештә җибәрелгән очракта, аны тикшерүче зат алган дип санала. Акт тапшыру хәбәрнамәсе һәм (яки) акт алуны раслау Дәүләт комитетының эшендә сакланган тикшерү акты нөсхәсенә кушыла»;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«- актны заказлы хат белән яки актны төзегән затның ныгытылган квалификацияле электрон имзасын куеп электрон документ формасында җибәрү: тикшерү актын төзегәннән соң бер эш көне эчендә»;

Түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Юридик зат, шәһси эшмәкәр тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр яки ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән килешмәгән очракта ул тикшерү актын алган көннән унбиш көн эчендә Дәүләт комитетына тикшерү акты һәм (яки) бирелгән күрсәтмә белән тулаем яки аның кайбер нигезләмәләре белән килешмәве турында язма рәвештә белдерергә хокуклы. Бу вакытта юридик зат, шәһси эшмәкәр мондый килешмәүләрнең нигезле булуын раслый торган документлар яки аларның имзаланган күчермәләрен теркәргә йә килешенгән вакытта аларны Дәүләт комитетына тапшырырга мөмкин. Күрсәтелгән документлар, тикшерүче затның ныгытылган квалификацияле электрон имзасы куелып, электрон документлар (электрон документлар пакеты) рәвешендә тапшырылырга мөмкин.»;

түбәндәге эчәлекле 5.2.11 пункты белән тулыландырырга:

«5.2.11. Җаваплы башкаручы тиешле мәгълүматны бердәм тикшерүләр реестрына «Бердәм тикшерү реестрын формалаштыру һәм алып бару турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары нигезендә кертә (әлеге абзацның таләпләре 2016 елның 1 июленнән гамәлгә керә).»;

5.3 пунктында:

5.3.4 пунктчасында:

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«Юридик затның җитәкчесе, башка вазифаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле урында булмаган очракта, шулай ук тикшерелгән зат тикшерү акты белән танышуы яки танышудан баш тартуы турында расписка бирергә баш тарткан очракта, акт почта аша тапшырылуы расланган заказ хаты итеп җибәрелә, ул исә Дәүләт комитеты эшендә сакланган тикшерү акты нөсхәсенә кушыла. Тикшерелгән затның хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашыру ризалыгы булганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тикшерү акты электрон документы формасында, шушы актны төзүче затның ныгытылган

квалификацияле электрон имзасы куелып, җитәкчегә, башка вазифаи зат яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиленә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта электрон формада җибәрелгән, аны төзүче затның ныгытылган квалификацияле электрон имзасы куелган акт тикшерүче затка күрсәтелгән документның барып җитүен раслаучы рәвештә җибәрелгән очракта, аны тикшерүче зат алган дип санала. Акт тапшыру хәбәрнәмәсе һәм (яки) акт алуны раслау Дәүләт комитетының эшендә сакланган тикшерү акты нөсхәсенә кушыла.»;

унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«- актны заказлы хат белән яки актны төзегән затның ныгытылган квалификацияле электрон имзасын куеп электрон документ формасында җибәрү: тикшерү актын төзегәннән соң бер эш көне эчендә;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Юридик зат, шәһси эшмәкәр тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр яки ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән килешмәгән очракта ул тикшерү актын алган көннән унбиш көн эчендә Дәүләт комитетына тикшерү акты һәм (яки) бирелгән күрсәтмә белән тулаем яки аның кайбер нигезләмәләре белән килешмәве турында язма рәвештә белдерергә хокуклы. Бу вакытта юридик зат, шәһси эшмәкәр мондый килешмәүләрнең нигезле булуын раслый торган документлар яки аларның имзаланган күчермәләрен теркәргә йә килешенгән вакытта аларны Дәүләт комитетына тапшырырга мөмкин. Күрсәтелгән документлар, тикшерүче затның ныгытылган квалификацияле электрон имзасы куелып, электрон документлар (электрон документлар пакеты) рәвешендә тапшырылырга мөмкин.»;

түбәндәге эчтәлекле 5.3.8 пунктча  белән тулыландырырга:

«5.3.8. Җаваплы башкаручы тиешле мәгълүматны бердәм тикшерүләр реестрына «Бердәм тикшерү реестрын формалаштыру һәм алып бару турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары нигезендә кертә (әлеге абзацның таләпләре 2016 елның 1 июленнән гамәлгә керә).»;

5.4 пунктында:

5.4.1 пунктчасында «2.4.2 пунктында» сүзләрен «2.4.3, 2.4.4 пунктларында» сүзләренә алыштырырга;

5.4.5 пунктчасында:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«Әлеге документлар мөһер белән (әгәр дә булса) һәм хосусый эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең, җитәкченең, юридик затның башка вазифаи затының имзасы белән расланган күчермә рәвешендә җибәрелә. Юридик зат, шәһси эшмәкәр запроста күрсәтелгән документларны электрон формада, ныгытылган квалификацияле электрон имза куелып, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән рәвештә тапшырырга хокуклы.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Дәүләт комитеты тикшерүләрне оештырганда һәм үткәргәндә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлеккә кертелгән  документларны һәм (яки) мәгълүмәтларны түләүсез нигездә, шулай ул электрон формада, башка дәүләт

органнары, җирле үзидарә органнары яки дәүләт ораганнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары кармагында булган элеге документлар һәм (яки) мәгълүмәтларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларныда Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән срокларда һәм тәртиптә соратып ала һәм кабул итә (әлеге абзац таләбе 2016 елның 1 июленнән гамәлгә керә).»;

5.4.7 пуктчасында:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«Юридик затның җитәкчесе, башка вазыифаи заты ики вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләте вәкиле урында булмаган очракга, шулай ук тикшерелгән зат тикшерү акты белән танышуы яки танышудан баш тартуы турында расписка бирүдән баш тарткан очракта, акт почта аша тапшырылуы расланган заказлы хат итеп җибәрелә, ул исә Дәүләт комитеты эшендә сакланган тикшерү акты нөсхәсенә кушыла. Тикшерелгән затның хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашыру ризалыгы булганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тикшерү акты электрон документы формасында, шушы актны төзүче затның ныгытылган квалификацияле электрон имзасы куелып, җитәкчегә, башка вазифаи зат яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиленә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта электрон формада җибәрелгән, аны төзүче затның ныгытылган квалификацияле электрон имзасы куелган акт тикшерүче затка күрсәтелгән документның барып җитүен раслаучы рәвештә җибәрелгән очракта, аны тикшерүче зат алган дип санала. Акт тапшыру хәбәрнәмәсе һәм (яки) акт алуны раслау Дәүләт комитетының эшендә сакланган тикшерү акты нөсхәсенә кушыла»;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«- тикшерү актын төзү һәм тапшыру: тикшерү тәмамланганнан соң ук (тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшеренүләр нәтиҗәләре буенча бәяләмә, сынаулар, махсус тикшерүләр, экспертизалар кирәк булган очракта тикшерү акты контрольлек чаралары тәмамланганнан соң өч эш көненнән артык булмаган вакытка төзелә)»;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«- актны заказлы хат белән яки актны төзегән затның ныгытылган квалификацияле электрон имзасын куеп электрон документ формасында җибәрү: тикшерү актын төзегәннән соң бер эш көне эчендә;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Юридик зат, шәһси эшмәкәр тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр яки ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән килешмәгән очракта ул тикшерү актын алган көннән унбиш көн эчендә Дәүләт комитетына тикшерү акты һәм (яки) бирелгән күрсәтмә белән тулаем яки аның кайбер нигезләмәләре белән килешмәве турында язма рәвештә белдерергә хокуклы. Бу вакытта юридик зат, шәһси эшмәкәр мондый килешмәүләрнең нигезле булуын раслый торган документлар яки аларның имзаланган күчермәләрен теркәргә йә килешенгән вакытта аларны Дәүләт комитетына тапшырырга мөмкин. Күрсәтелгән документлар, тикшерүче затның ныгытылган квалификацияле

электрон имзасы куелып, электрон документлар (электрон документлар пакеты) рәвешендә тапшырылырга мөмкин.»;

түбәндәге эчтәлекле 5.4.10 пунктчасы белән тулыландырырга:

«5.4.10. Җаваплы башкаручы тиешле мәгълүматны бердәм тикшерүләр реестрына «Бердәм тикшерү реестрын формалаштыру һәм алып бару турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары нигезендә кертә (әлеге абзацның таләпләре 2016 елның 1 июленнән гамәлгә керә).»;

5.5 пунктында:

5.5.1 пунктчасында «2.4.2 пунктында» сүзләрен «2.4.3, 2.4.4 пунктларында» сүзләренә үзгәртергә;

5.5.4 пунктчасында «2.4.2 пунктының 2 пунктчасында» сүзләрен «2.4.3, 2.4.4 пунктларының 2 пунктчаларын» сүзләренә үзгәртергә;

түбәндәге эчтәлекле 5.5.10 пунктчасы белән тулыландырырга:

«5.5.10. Җаваплы башкаручы тиешле мәгълүматны бердәм тикшерүләр реестрына «Бердәм тикшерү реестрын формалаштыру һәм алып бару турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары нигезендә кертә (әлеге абзацның таләпләре 2016 елның 1 июленнән гамәлгә керә).».

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккач 10 көннән соң гамәлгә керә.

3. Әлеге боерыкның үтәлеше үз күзәтчелегем астында кала.

Рәис М.Р.Зарипов